ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫАЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 15.09.2025 1499 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2024 елның 27 декабрендәге 2220 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга Санитар - эпидемиологик таләпләр» санитар нормалар һәм кагыйдәләрнең 2.3/2.4.3590-20 номерлы балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген ныгыту, белем бирү учреждениеләрендә укучыларны балансланган кайнар аш белән тәэмин итү нормаларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2024 елның 27 декабрендәге 2220 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 2.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Гомуми белем бирү муниципаль оешмаларында түбәндәгеләрне билгеләргә:

- туклануга компенсация түләүләренең күләме -10 сум 30 тиен;

- бер укучыга көненә бер тапкыр кайнар туклануның уртача бәясен:

1-4 сыйныфта укучы балаларга – 74 сум 77 тиен (федераль акчалар исәбенә) күләмендә;

5–11 сыйныфта укучы балаларга – 80 сум күләмендә (10 сум 30 тиен җирле бюджет акчасыннан түләнә, 69 сум 70 тиен ата-аналар түләве хисабына);

- озайтылган көн төркемнәрендә йөрүче балаларны тукландыруның уртача бәясе - 65 сум 00 тиен (ата-аналар акчалары исәбеннән);

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» ББМБУ кадет сыйныфларында укучы балаларга көненә


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

уртача туклану бәясе - 155 сум 30 тиен күләмендә (10 сум 30 тиен җирле бюджет акчаларыннан, 145 сум ата-аналар түләве хисабына түләнә);

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Инженер-технология лицее» ББМБУнең спорт сыйныфларында укучы балаларга көненә уртача туклану бәясе - 310 сум күләмендә (77 сум 50 тиен җирле бюджет акчаларыннан, 77 сум 50 тиен йөзү федерациясе тарафыннан, 155 сум ата-аналар түләве хисабына түләнә);

- 1 - 11 сыйныфта укучы балаларга (сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар, инвалидлар, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләрендәге укучы балаларга) - 145 сум күләмендә;

- шикәр диабеты белән авыручы балаларга көненә уртача индивидуаль тукландыруның уртача бәясе-74 сум 77 тиен күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026

Р.Э. Әхмәдиева

Лист согласования к документу № 1499 от 15.09.2025
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 16.09.2025 13:33

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 16.09.2025 - 15:22 | - |